ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР № 32

Акбаш ав.

«23» ноябрь 2023 ел

Акбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның
05 ноябрендәге “Физик затлар милкенә салым турында”гы
26 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексы, 2014 елның 30 октябрендәге «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибенең бердәм датасын билгеләү турында»гы 82-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Акбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 05 ноябрендәге “Физик затлар милкенә салым турында”гы 26 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1) Түбәндәгеләргә карата 0,1 процент:

- торак йортлар, торак йортларның кайбер өлешләренә, фатирлар, фатирларның кайбер өлешләренә, бүлмәләрнең өлешләренә;

- төгәлләнмәгән төзелеш объектлары, әгәр мондый объектларның проектланган билгеләнеше торак йорт булса;

- составына бер генә торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплекслар;

- гараж һәм машина урыннары, шул исәптән Россия Федерациясе Салым кодексының 2 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларында урнашкан урыннар;

- хуҗалык корылмалары яисә төзелешләре, аларның һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган очракта һәм алар шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яисә шәхси торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан булса;

2) Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 маддәсендәге 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 маддәсендәге 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата, шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2 процент;

3) салым салуның башка объектларына карата 0,5 процент.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасының Бердәм муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге башлыгы
вазифасын башкаручы Г.Ф.Хаҗиева